Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
Ирекле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

2 декабрь 2025 ел №13

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 10 сәгатьтә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. 2025 елның 1 декабрендә 00 минут, 2025 елның 1 декабрендә 12 сәгать 00 минут, 2025 елның 1 декабрендә 14 сәгать 00 минут, 2025 елның 1 декабрендә 16 сәгать 00 минут: «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Ирекле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәтне узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаиләәгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә җибәрү белән килешәсезме:

- чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су җыю манарасын һәм аңа комплектлаучы әйберләрне сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү торбаларын һәм аларга комплектлаучы әйберләрне сатып алу һәм алыштыру)?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе тезелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 133 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 67 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 36 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 31 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ирекле авыл җирлегенең Иске Михайловка авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.«Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Ирекле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәтне узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә җибәрү белән килешәсезме: чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су җыю манарасын һәм аңа комплектлаучы әйберләрне сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү

торбаларын һәм аларга комплектлаучы әйберләрне сатып алу һәм алыштыру)» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Михайловка авылы, Школьнаяурамы, 43 йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йортытерриториясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 кен эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин